Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

23.09.2017 ел № 52

«Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен раслау һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлешен, «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.3 өлешен, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре» 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указының 8 пункты нигезендә Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы,

Кама Тамагы Иске Казиле авыл җирлеге Советы Рәисе И. Х. Сәгъдиев